**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**28.10.2019 ел** **№5**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, к а р а р б и р д е:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Сарысаз-Тәкермән авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 14 ноябрenә 09.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2020 елда үзара салым акчасын 300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

- Сарысаз-Тәкермән торак пунктының Карл Маркс, Чапаев урамы буенча юлларга вак таш җәю (таш ташу);

-Сарысаз-Тәкермән торак пунктының җирле әһәмияттәге юлларын кышын кардан чистарту;

- Сарысаз Тәкермән торак пунктында Сабантуй бәйрәмен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

-Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу;

-Сарысаз Тәкермән торак пунктларында урам утларын ремонтлау (лампаларны алыштыру ;

"ӘЙЕ" "ЮК".

3.Иске Имән авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Иске Имән, Сарысаз Тәкермән авыллары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Имән авыл җирлеге башлыгы: Р.Ә.Исламова

СОВЕТ СТАРО-ИМЯНСКОГО сельского поселения ОГРН 1021601312979 ИНН 1636001989